КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 апрель г.Казань № 315

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга каршы тору мәсьәләләре буенча актлар һәм башка документлар проектларын әзерләү һәм тапшыру тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләренә эшләргә, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга каршы тору мәсьәләләре буенча актлар һәм башка документлар проектларын (алга таба – документлар проектлары), тиешле йөкләмәне (күрсәтмәне) алган вакыттан соң, ведомствоара килештерү вакытын да кертеп, 24 сәгатьтән дә артмаган вакыт эчендә әзерләүне һәм тапшыруны тәэмин итәргә, әгәр йөкләмәдә (күрсәтмәдә) аларны әзерләүнең башка вакытлары каралмаган булса;

документлар проектларын, алар кергән вакыттан алып дүрт сәгатьтән дә артык вакыт эчендә килештерергә;

әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән срок арткан очракта, документ проектын килештерелгән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты бүлекчәләре җитәкчеләренә, документлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кергәннән соң 24 сәгатьтән дә артмаган вакыт эчендә документлар проектларын эшләүне, килештерүне һәм имзалауга тапшыруны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х. Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин